ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 статьяның 1 өлешендә «3.2 – 3.6» саннарыннан соң «, 3.16, 3.17, 3.19» саннарын өстәргә;

2) 3.6 статьяның 1 өлешендә «3.17 статьясында» сүзләрен «3.17, 3.19 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3.16 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – ике мең биш йөз сум; юридик затларга биш мең сум күләмендә административ штраф салына.»;

4) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.19 статья өстәргә:

«3.19 статья. **Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенә таләпләрне бозу**

Йөк транспорты чарасын кузовтагы (контейнердагы) чәчелүчән йөкләрне, чүп-чарны, җиңел әрҗәне, киселгән агачларны, яфракларны брезент яисә башка материал белән капламыйча файдалануда чагылган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенең җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләрен бозган өчен –

гражданнарга – биш мең сум; юридик затларга илле мең сум күләмендә административ штраф салына.»;

5) 7.4 статьяда «3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәргә;

6) 8.1 статьяның 14 өлешендә «3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәргә;

7) 8.3 статьяда «3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), «3.14 – 3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 25 июнь
№ 46-ТРЗ